КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 15 февраль г.Казань № 88

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 ел, 6 июль, 561 нче номерлы карары белән расланган Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык өлкәсендә чараларны тормышка ашыру өлешендә җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен башкарганда барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен финанслашу өчен Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләре бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык өлкәсендә чараларны тормышка ашыру өлешендә җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен башкарганда барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен финанслашу өчен Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләре бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибен раслау турында» 2020 ел, 6 июль, 561 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 ел, 18 ноябрь, 1032 нче, 2020 ел, 25 декабрь, 1189 нчы, 2021 ел, 27 апрель, 287 нче, 2021 ел, 13 декабрь, 1213 нче, 2024 ел, 3 август, 619 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык өлкәсендә чараларны тормышка ашыру өлешендә җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен башкарганда барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен финанслашу өчен Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләре бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

11 пунктның дүртенче абзацында «тәртибе» сүзеннән соң «һәм сроклары» сүзләрен өстәргә;

13 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«13. Башка бюджетара трансфертлар килешүдә каралган срокта Министрлык тарафыннан Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсендә муниципаль берәмлекнең финанс органына ачылган муниципаль район бюджетының бердәм счетына күчерелә.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин